ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**13.12.2019** **№ 2390**

## 2020 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 бүлегендәге 11 пункты, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында”, 2008 елның 30 апрелендәге 279 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга теркәлгәннәрне расларга:

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү учреждениеләре мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны.

2. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Финанс-бюджет палатасына, мәгариф оешмаларын финанслауны түбәндәгеләр белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә тәэмин итәргә:

“2020 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында”, 2019 елның 2 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге” рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 нчы гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р.Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Расланган
“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карары белән
13.12.2019 № 2390

**“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы интернатларда  һәм гомуми белем бирү учреждениеләре мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү учреждениесе каршындагы интернат | авыл җирлеге | 92342 |
| Гомуми белем бирү мәктәп-интернаты | авыл җирлеге | 141713 |